**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Кирлегәч авылында Амур урамында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау эшләре (вак таш салу, смета буенча түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы Кирлегәч авылы, Совет урамы, 33а йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы С.Р.Сәлахова